

/Котлыйбыз!/

## Өлкәннәр көне белән!

Октябрьнең беренче көнендә өлкәннәр бәйрәме булды. Анда укытучылар лаеклы ялда булган өлкән укытучыларны котларга бардылар. Кайбер укучылар рәсем ясадылар һәм котлау язып әби-бабайларын шатландырдылар. Алар бик шатланып һәм яратып фотога төштеләр. Чөнки бөтен кешенең әбиләре һәм бабайлары бар. Минем дә ике әбием һәм бабам бар. Мин аларны бик тә яратам.

***Фаил Нургатин, IVсыйныф укучысы***

## 20нче октябрь – пешекчеләр көне

Безнең укытучылар бәйрәме белән бер айда пешекчеләр көне дә билгеләп үтелә. Алар да мәктәп тормышының мөһим бер юнәлешен алып баручылар. Тамагы тук, яраткан ризыгын ашаганда гына бала фикерен укуга юнәлтә ала. Ә безнең пешекчеләребез бу эшен яратып, төгәл итеп, һәр көнне бәйрәмчә өстәл корып, балаларыбызны тукландыралар. Аларга ярдәм итүче җыештыручы апаларга да без бик рәхмәтле. Барысына да җаваплы эшләрендә уңышлар, сәламәтлек теләп калабыз.

***"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе***






Октябрь аенда дөньяга килгән дусларыбыз – IV сыйныфтан **Закиров Инсафны**, VIII сыйныфтан **Хәбибрахманова Хәнифәне**,IXсыйныфтан**Нургалиева Ләйләнетуган** көннәре белән котлап,ныклы сәламәтлек, укуларында уңышлар теләп калабыз!

Башлангыч сыйныф укытучысы **Камалова Сирин апаны** гомер бәйрәме белән котлап, саулык-сәламәтлек, эшендә уңышлар, гаилә иминлеге телибез!

***Мәктәп коллективы***

/Укучылар иҗаты/

## Изгелек җирдә ятмый

Борынгы заманда урманда Куян белән Тиен яшәгәннәр. Алар үзара да бик дус булганнар,башка хайваннар белән дә кунакка йөрешкәннәр, ди. Көннәрдән бер көнне алар төлкегә кунакка барырга җыеналар. Үзләре белән күршеләре Керпене дә чакырырга булалар. Керпе күчтәнәчкә дип бер зур алма алып аркасына сала. Ләкин биек ярлы күл буена җиткәч алмасы әнәләреннән ычкынып, күлгә тәгәрәп төшә. Бу күлнең патшасы зур гына Шүкә балыгы икән. Күлгә төшкән бөтен нәрсә аның байлыгы саналган, ди. Шуңа күрә Шүкә үзенең балыкларына алманы келәтенә кертеп куярга боерган.



Күчтәнәчен югалтудан Керпе бик кайгыга баткан инде. Аны юату өчен, Тиен тиз генә өенә кайтып, кышкыга сакларга куйган бер алмасын керпегә алып килеп бирә. Шул арада Керпенең кайгысын ишеткән Аю да үз хәзинәсеннән бер алма китерә. Ярда булган хәлне ишеткән балыклар бу хәлләр турында Шүкәгә җиткерәләр. Шүкә күлгә төшкән алманың Керпенеке икәнен белгәч, аны хуҗасына чыгарып бирергә куша.

Керпе урмандагы иптәшләренең бу яхшылыкларына исе китә һәм бик күп рәхмәтләр әйтә. Дуслары үзләре дә керпедән бик күп яхшылыклар күргән булганнар. Карт аю аңа: ,,Бер рәхмәт мең бәладан коткара" – ди. Шуннан соң барысы бергә төлкегә кунакка барырга булалар. Шул вакыттан бирле урман хайваннары бер-берсенә ярдәм итеп, матур гына яшәп яталар ди.

***Гөлсем Сафиуллина, IVсыйныф укучысы***



## Икмәк безгә кайдан килә?

/Безнең сәяхәтләр/

Икмәк, ипи, ипекәй...һәр табынның түрендә зур урын алып торган бу ризык ничек пешерелә соң? Әлеге сорауга җавап табу өчен, 12 октябрь көнне без укучылар белән Аксубайдагы икмәк пешерү цехында бардык. Анда эшләүче апалар безне якты йөз белән каршы алып, икмәкнең табынга нинди юллар аша килүе белән таныштырдылар. Безгә бу эшләрнең ничек эшләнүен күрү бик кызык булды. Кунактан тәмле күчтәнәчләр белән дә кайттык.

Тәмледән-тәмле ипи һәм башка ризыклар пешерүче апаларга зур рәхмәтебезне белдерәбез!

***Инсаф Закиров, IV сыйныф укучысы***

**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:** Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Төхвәтуллин

# Мәктәп хәбәрчесе

**№7**
(№58)
сентябрь
2024 ел

Түбән Майна урта мәктәбе газите

Тел. 8 (84344) 4-38-46
sch1644maina@mail.ru

/Мөхәррир минбәре/

## Бердәм булыйк!




2024нче ел – илебездә Гаилә елы дип игълан ителгәнне язып үткән идек инде. Шушы теманы дәвам итеп, ГАИЛӘ белән МӘКТӘП аерылгысыз төшенчә булганлыгын билгеләп үтәсебез килә. Психологик статуслары буенча алар капма-каршы. Гаиләдә бөтен нәрсә эмоциональ бәйләнешләргә нигезләнгән, ә мәктәпнең функцияләре башкачарак. Аның максаты балага туган йортын алыштыру түгел, ә баланы укыту, танып-белү сәләтен үстерү, талантын ачу.

Бала зур уңышларга ирешү өчен мәктәп белән гаилә бер юнәлештә эшләргә тиеш. Әгәр ата-ана баласының укуы белән даими кызыксынып торса, өй эшләрен контрольдә тотса, файдалы киңәшләрен бирсә, билгеле, укучы яхшырак укыячак. Киресенчә булган очракта укучының укуга карашы тискәре якка үзгәрәчәк. Шул бергәлекне тәэмин итәрлек мөмкинлекләребез көннән-көн арта. Интернет ярдәмендә "МОЯ ШКОЛА"га тоташып, бүгенге көндә баланың нинди өй эшләре барлыгын, һәр көнне нинди билге алганын да тәүлекнең теләсә кайсы вакытында карап була.

Баланы инсафлы, әдәпле, мәрхәмәтле, белемле, җәмгыятькә файдалы шәхес итеп тәрбияләү – мәктәп белән гаиләнең изге бурычы. Ике як бердәм эшләгәндә генә зур нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин. Мәктәп белән гаиләнең бер юлдан атлавында төп рольне сыйныф җитәкчесе уйный. Сыйныф җитәкчесе укучыларының гаилә хәлләре, гаилә тәрбиясенең үзенчәлекләре, яшәү шартлары белән хәбәрдар була.

Кеше гомере буена гаиләдә генә бикләнеп яши алмый. Ул җәмгыятькә кереп китсен өчен, андагы уңай тәртипләргә яраклашырга тиеш. Ата-аналар иң беренче чиратта үзләре дә мәктәп тормышы, анда кабул ителгән тәртип-кагыйдәләр белән таныш булырга, үз балаларының әнә шул кагыйдәләрне үтәвенә дә йогынты ясарга бурычлы. Моның өчен аларның сыйныф җитәкчесе белән дә, фән укытучылары белән дә элемтәдә тора ала. Бүгенге көндә элемтәгә чыгуның берничә кыенлыгы булмау – әти-әниләрнең зур мөмкинлеге. Моның өчен вакыт та күп кирәк түгел, каядыр барасы да түгел. Кемнеңдер ярдәме дә кирәкми. Турыдан-туры элемтәгә чыгу - үзара аңлашылмаучанлыктан коткарыр. Әңгәмә барышында бер-береңнең ышанычын яуларга, укучы бала хакында нинди дә булса тискәре фикер әйтелгәндә дә, моның бары тик изге нияттән эшләнүен төшенеп була. Ата-ана белән сөйләшү барышында ачыкланган хәлләрне башкаларга таратмый калырга да мөмкин.

Хөрмәтле әти-әниләр! Сезнең балалар - безнең кадерле, яраткан укучыларыбыз. Нинди генә очракта да, алар безнең уртак хезмәтебез. Әмма укытучы никадәр көч түкмәсен, чын тәрбия берьяклы гына була алмый. Тәрбиянең төп асылы – мәктәп белән гаиләнең бердәмлегендә.

***Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир***

## 5нче октябрь– Укытучылар көне



*Күркәм бәйрәм мәктәптә-*
*Укытучылар көне!*
*Бүләк итәбез аларга*
*Гади чәчәк бәйләме!*
*Гади генә холкы белән,*
*Кирәк чакта сабыр да.*
*Бераз гына усал булып*
*Аңлаталар барын да.*
*Елмайтабыз бүген Сезне,*
*Гади олы бәйрәмдә.*
*Күңелегезне күтәреп*
*Килачәк көннәргә дә.*
*Тыңлаучан һәм дә зирәк*
*Укучылар килсеннәр.*
*Алган белемнәреңнең*
*Кадерләрен белсеннәр.*
*Сәламәтлек һәм сабырлык*
*Юлдашыгыз булсыннар.*
*Иҗади хезмәтегез*
*Эзсез югалмасыннар!*

***Хөрмәтле укытучылар! Сезне чын күңелдән һөнәри бәйрәмегез белән котлый-быз. Мактаулы хезмәтегездә зур уңышлар, иҗади сәләт, олы сабырлык, замана белән бергә атлап, чын дустыбыз да булуыгызны телибез.***

*Бәйрәм белән котлап, "Мәктәп хәбәрчесе"редколлегиясе*

## I чирек нәтиҗәләре

**/Рәсми хәбәрләр/**

Октябрьнең 26 сында уку елының I чиреге дә тәмамланды. Бу чиректә 39 укучының 37 сенә билгеләр чыгарылды. Белем сыйфаты 62% тәшкил итте. Уку отличниклары – II сыйныфтан **Хәйруллин Мансур**, IIIсыйныф укучысы **Гафиятуллина Руфинә** һәм VIII сыйныф укучысы **Гафиятуллин Фаил**. Көзге каникуллар 28 нче октябрьдән 6 нчы ноябрьгә кадәр дәвам итәчәк.



## Уңыш бәйрәме

**/Безнең бәйрәмнәр/**

Быелгы Уңыш бәйрәме аеруча да кызык булды. Башка елларны без Уңыш бәйрәмен шигырьләр ятлап, кунаклар каршы алып уздыра идек. Бу юлы исә, бәйрәм безнең өчен булды.



Бәйрәм башында без кызыклы уеннар уйнадык. Көзгә кагылышлы сынамышлар-ны искә төшердек, табышмакларга җаваплар эзләдек. Миңа аеруча тәм тою уены бик ошады. Апалар күзләрне бәйләп төрле яшелчә, җиләк-җимешләрне каптырдылар, ә без аларның тәмен тоярга тиеш идек. Миңа аеруча да тәмле яшелчә – сарымсак әләкте.

Бәйрәмдә без уйнап кына калмадык, үзебезне хезмәт ягыннан да сынадык. Кызлар матур итеп икмәк кисеп күрсәтте, ә без кызларга көч биреп тордык. Шулай ук бергәләшеп винегрет салаты өчен яшелчәләр турадык. Бу салат безнең бик тә тәмле килеп чыкты. Ә иң кызыгы соңыннан бергәләшеп чәй эчү булды. Мин мондый бәйрәмнәрнең күбрәк булуын теләр идем.

***Инсаф Закиров, IV сыйныф укучысы***



## КВН – файдалы уен

Безнең гадәткә кергән, һәркем көтеп алган бәйрәм –Уңыш бәйрәме шаулап узды. Быел да традициягә тугры калып, командаларга бүленеп ярыштык. Биремнәребез дә җыр, бию, реклама, клип, скетч, мода күрсәтүдән гыйбарәт иде. “Алга” һәм “Бердәм”командаларын җитәкләгән Кадырова Гөлнур апа белән Сафиуллина Алсу апа безнең уңышлы чыгышыбыз өчен бик тырыштылар. Команда белән эшләүнең уңай ягы күп булганга, бу бәйрәм һәрберебезгә ошый. Чөнки бер эшне берничә иптәшең белән башкарып чыгу өчен барлык мөмкинлекләрдән файдаланырга тырышасың, эзләнәсең. Кемнеңдер шул вакытта оештыру сәләте ачыла. Кайберләребезнең сәхнәдә үзен тотарга өйрәнүе шуннан башлана. Тапкырлыкка, зирәклеккә, җитезлеккә өйрәтүе белән файдалы ул КВН.

Без дә иң элек исем уйлаудан тотындык. Аңа якын булган девизны, җырны эзләдек. Биремнәрне үтәр өчен никадәр театр карап чыктык. Бию төрләрен өйрәндек. Кул астында булган чималлардан тормыш өчен кирәге булган вак-төякләр ясадык. Командаларның ярыш нәтиҗәләрен караганда,без ныклы команда идек. Ләкин ярыш – ярыш инде ул. Җиңү яулау гына түгел, җиңелә дә беләбез. Шулай итеп, “Бердәм” командасы 76 балл белән беренчелеккә чыкты, ә “Алга” командасы 72 балл белән җиңелде.

***Самат Гафиятуллин, XI сыйныф укучысы***



**/Мәктәп тормышы/**

## Финанс белемлелеге буенча яңа сезон башланды

12 октябрь көнне мәктәбебездә тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Насыйров Рәфикъ абый катнашында финанс белеме дәресе үткәрелде. Дәрестә финанс яктан грамоталы кешенең белемнәре һәм компетенцияләре, аерым алганда, шәхси финанс планы, кредитлар, инвестицияләр, иминиятләштерү, финанс иминлеге, үз бюджетыңны формалаштыру турында сүз барды. Болардан тыш,финанслар өлкәсендә башкарма хакимиятнең, закон чыгару органнарының роле, төрле оешмалар һәм аерым гражданнарның мөмкинлекләре каралды. Рафик абый шулай ук проект кысаларында өлкән сыйныф укучыларын “Бердәм Россия” партиянең Халык программасы белән таныштырды һәм аны өйдә эти-әниләр белән фикер алышырга тәкъдим итте. Безне кызыксындырган күп кенә сорауларга җавап биреп, югары сыйныф укучыларына һөнәр сайлау буенча үзенең киңәшләрен җиткерде.

***Зәйнәп Нурматова, XIсыйныф укучысы***

**/Күренекле шәхесләр/**

## Авылда яшәп калуым белән бәхетле



Кеше гомеренең һәр дәвере үзенең нинди дә булса бер үзенчәлеге белән истә кала. Балачактагы матур истәлекләр арасында шактый зур урынны мәктәп, дуслар һәм, әлбәттә инде, барчабызга да ярдәмче, киңәшче, төпле белем бирүче шәхесләр – укытучылар алып тора. Мәктәп – икенче өй булган кебек, укытучы – икенче әни, икенче әтидер инде ул. Менә шул хезмәтне җиренә җиткереп, төгәл башкарган шәхесләр арасында, тиз арада балаларыбыз яратып өлгергән, инде бу уку елыннан лаеклы ялга киткән Зарипов Фәнил Закир улы белән булыр әңгәмәбез.

**- Фәнил абый, укытучы һөнәренә ничек килдегез? Балачак хыялымы, әллә берәр этәргеч булдымы?**

- Балачакта укытучы булырмын дип хыялланганымны хәтерләмим. Югары сыйныфларда укыганда гына укытучы булу теләге туды. Бу вакытта инде бертуган апам укытучы булып эшли иде. Укытучы һөнәренә мәхәббәт аңа карап уянгандыр, мөгаен.

**-Үзегезнең холкыгыз кебек төгәл фәнне сайлагансыз. Бу очраклымы, максатчан хәлме?**

- Очраклы түгел дип уйлыйм. Мәктәптә укыганда ук математика дәресләрен бик ярата идем. Ул гына да түгел, минем өчен үрнәк алырлык кеше – Такталы авылы сигезъеллык мәктәбе математика укытучысы Галиева Миннися апа булды.

**- Укытучы белгечлеген кайсы югары уку йортында алдыгыз?**

- Укытучы белгечлегенә 1980-1984нче елларда Казан Дәүләт педагогия институтының физика-математика бүлеген тәмамлап ия булдым.

**- Мәктәптә гомер буе бер генә юнәлештә эшләдегезме?**

- Әйе, мәктәптә эшләү дәверендә математика фәнен генә укыттым.

**- Мәктәптә балалар белән эшләү җиңел хезмәт түгел. Сезгә кыенлыклар күп булдымы, әллә яраткан эшнең күңелсез яклары күренмиме?**

- Укытучы хезмәте җиңел түгел. Шул ук вакытта ул дөнядагы иң кызыклы, хөрмәтле һәм таләп ителгән һөнәрләрнең берсе инде ул. Үз гомеремдә күпме эчкерсез җаннарга белем диган гаҗәеп сихри дөнья ишекләрен ачарга, алар күңелен җир йөзендә булган иң-иң яхшы сыйфатлар белән бизәргә тиешлегемне әле укуны тәмамлап кайтып, мәктәптә эшли башлаганда, аңлап та бетермәгәнмендер, мөгаен. Бүген менә уйланам да, хәйран калам. Укытучы хезмәте искиткеч җаваплы бит. Эшләү дәверендә күпме йокысыз төннәр, керфек какмый аттырылган күпме таңнар. Түгелгән күпме көч, иҗади эзләнүләр, кызыклы нәтиҗәләр-барысы да укучыларның шәхси үсешенә уңай йогынты ясау өчен башкарыла. Укучыларның уңышлары-укытучы өчен иң зур бәхет. Аларның уңышлары, җиңүләре –бөтен мәшәкатьләрне, ару-талуларны, яну-көюләрне оныттыра. Ә укытучы өчен иң зур бүләк – укучыларның рәхмәте. Безнең өчен иң кадерлесе, иң әһәмиятлесе, куанычның иң зурысы – күп еллар үткәч тә, кайчандыр үзең укыткан укучының елмаеп килеп исәнләшүе, хәл белешүе.

**- Балалар йөрәгенә юл табу һәр чор өчен бер үк төслеме, замана белән үзгәрәме?**

- Хәзерге заман укучысы мәктәптә эшли башлаган еллардагы укучылардан күпкә аерыла. 90нчы еллардагы укучылар газета-журналлар, матур әдәбият китаплары укый иде. Ә бүгенге баланы китап укытып булмый. Тик бу хәзерге заман баласы начар диган сүз түгел. Бүгенге көн укучылары заманча яңа технологияләрдән хәбәрдар.

**- Ничә ел гомерегез мәктәп, укучылар арасында үтте.**

- Минем бөтен хезмәт елларым мәктәптә, укучылар арасында үтте, балаларга 37 ел математика фәнен укыттым.

**- Туган авылда яшәү һәм эшләвегезне ничек кабул итәсез?**

- Уку йортын тәмамлагач, Казанда да торып кала ала идем. Диплом алгач, инженер булып эшләргә тәкъдим ясаганнар иде. Ләкин минем күңелгә авыл тормышы якынрак булды. Һәм мин авылда яшәп калуым белән бәхетле.

**- Мәктәп укучыларына нинди теләкләр әйтер идегез?**

- Кадерле укучылар! Уку елы сезнең өчен кызыклы һәм уңышлы булсын! Тырышып укыгыз һәм белемнең зур байлык икәнен онытмагыз! Белемегез көннән-көн арта барсын, ә укуыгыздагы уңышлар сезгә шатлык һәм канәгатьлек китерсен. Белем һәм осталыкларыгызны төрле бәйге-ярышларда, олимпиадаларда күрсәтерсез диган өметтә калам. Барыгызга да сәламәтлек, имин тормыш, куанычлы көннәр телим.

**- Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Фәнил абый. Сәламәтлек, гаиләгезгә иминлек теләп калабыз. Укучыларыгыздан һәрдаим рәхмәт сүзләре генә ишетелсен.**

***Ветеран укытучы белән әңгәмәне Самат Гафиятуллин һәм Зәйнәп Нурматова язып алды***